ҖОМГА
22
ЯНВАРЬ
1943 ел.
№ 18 (6740)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ һӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ һӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ

Ленин — Сталин байрагы астында без җиңәрбез!

1943 нче елның 21 нче январенда В. И Ленинның үлүенә XIX ел тулуга багышланган тантаналы-траур утырышында иптәш А. С. Щербаков доклады

Иптәшләр! Советлар Союзы халыклары, Кызыл Армия һәм Хәрби Диңгез Флоты бөек Ленин үлүгә 19 ел тулу көнен ватаныбызның намусы һәм бәйсезлеге өчен, үзләренең хәзерге һәм киләчәктәге тормышлары өчен, немец-фашист басып алучыларга каршы ватан сугышы шартларында искә алалар.

Үткән ел бөек сыналулар елы булды, сугышларның иң зурысы чорында партиябезнең, илебезнең юлы дөреслекне тарихи яктан зур тикшерү елы булды. Җәелеп киткән бәрелешләренең күләмнәре ягыннан да, Советлар Союзына каршы чыккан дошман армияләренең, безнең илебезне юк итүне, халкыбызны кол итүне һәм кырып бетерүне үзләренә максат итеп куйган армияләрнең характеры ягыннан да дөньяның мондый сугышны күргәне юк иде.

Сугыш совет строеның көчләренә һәм ныклыгына каты сынау булды. Узган елны безнең дәүләтебез үз өстенә төшкән сыналулардан намус белән үтте. Узган ел эчендә совет халкы һәм Кызыл Армия, үзенең юлбашчысы һәм полководецы иптәш Сталин җитәкчелегендә, сугышның барышын үзгәрттеләр һәм тагын да зуррак булган яңа уңышлар өчен нигез әзерләделәр. Узган ел Совет власте яшәүнең иң авыр чорында ленинизмның тантанасы елы булды.

СОВЕТЛАР СОЮЗЫНЫҢ СУГЫШ ХӘЛЕ

19 ай инде Кызыл Армия ватан сугышы фронтларында бик каты сугышлар алып бара. Соңгы айларда сугышның барышында җитди үзгәрешләр булды. Хәзер инде, 1942 нче елның җәендә һәм көзендә булган кебек, немецлар безнең гаскәрләрне кысрыкламыйлар, бәлки явыз дошманны Кызыл Армия кыйный һәм совет җирен гитлерчы пычраклардан чистарта. Хәзер инде сугыш хәрәкәтләрендә инициативаны немецлар һәм аларның иярченнәре үз кулларында тотмыйлар, бәлки Кызыл Армия, Верховный Баш Командование планы буенча хәрәкәт итеп, дошманга бер-бер артлы ударлар ясый.

Дәүләтебезнең хәзерге сугыш хәле турында кыскача гына уйлап карау, ватан сугышының хәзерге этабында сугышучы якларның хәлен чагыштырып карау белән үк безнең армиябез ирешкән җитди хәрби нәтиҗәләр ачык булып күренәчәкләр, сугыш алып баруның Советлар Союзы өчен уңайлы булган перспективалары ачык күренәчәкләр. Моның чыннан да шулай икәнлеген фактлар күрсәтәләр.

1942 нче елның җәендә һәм көзендә үк инде Кызыл Армия үзүзен аямыйча көрәшеп, немец гаскәрләренең авантюристлык планнарын өзде. Бөек Октябрь Социалистик революциясенең 25 еллыгы турындагы докладында иптәш Сталин тарафыннан бик ачык итеп күрсәтелгәнчә, Гитлерның 1942 нче елның җәендә һәм көзендә немец-фашист армиясе алдына куйган стратегик бурычларының берсе дә тормышка ашырылмады.

Немецлар һәм аларның союзниклары, Европада икенче фронт булмаудан файдаланып, үзләренең барлык буш резервларын Кызыл Армиягә каршы ташладылар. Немецларның планы Сталинградны алудан, Москваны көнчыгыштан әйләнеп үтүдән, аны Волга һәм Урал тылыннан аерудан, ә соңыннан Москвага удар ясап, 1942 нче елны сугышны тәмам итүдән гыйбарәт иде. Бу планны тормышка ашыру өчен Гитлер Сталинградка дистәләрчә иң яхшы дивизияләрен җибәрде. Күп атналар буена йөз меңнәрчә немецлар, совет җиренең һәрбер километрын үзләренең үле гәүдәләре белән каплап, Сталинградка ыргылдылар.

Шуның өстенә немецлар, барыннан да элек, Москва белән эшне тизрәк бетерү өчен, шулай ук нефтьне басып алу өчен, безнең резервларны Москва фронтыннан читләтү максаты белән көньякка, нефть районнарына таба ярдәмче удар ясадылар. Ләкин бу планнар, аларның үз көчләрен һәм Кызыл Армиянең көчләрен реаль төстә исәпкә алмыйча, комга корылганнар иде, ягъни авантюристлык планнары булып чыктылар.

Безнең илебез һәм Кызыл Армиябез җәй һәм көз айларында гитлерчы урдаларның котырынган басымына каршы нык тордылар, гаять бөек геройлык, нык торучанлык күрсәттеләр һәм немецларның стратегик планнарын аударып ташладылар.

Совет кораллы көчләренең Верховный Баш Командованиесе немецлар командованиесенең планнарын бетереп кенә калмады, бәлки куәтле җавап удары да әзерләде. 1942 нче елның 19 нчы ноябрендә Кызыл Армия һөҗүмгә күчте һәм Сталинградка килү юлларында немец-фашист гаскәрләрне тар-мар итү буенча Сталинның стратегик планын бик яхшы итеп тормышка ашырды. Сталинградка килү юлларында һөҗүм барган 6 атна эчендә генә дә Кызыл Армия дошманның 36 дивизиясен тәмам тар-мар итте һәм 22 дивизиясен тыгыз боҗра белән чолгап алды. Хәзер Сталинград районында чолганып калгач немец-фашист гаскәрләрне бетерү тәмам булуга якынлашып килә. Юлбашчыбыз һәм полководецыбыз иптәш Сталин исеме белән аталган шәһәргә килү юллары немец-фашист басып алучылар өчен гаять зур кабер булып әверелде. (**Көчле кул чабулар**).

Аннан соң Кызыл Армия, Сталинның стратегик планын тормышка ашырып, һөҗүм хәрәкәтләрен Төньяк Кавказга, Үзәк фронтка, Донның түбәнге агымы районына, Төньяк Донец районына, Воронеждан көньяктарак булган районга һәм Ленинград янына күчерде һәм бу юнәлешләрнең барысында да зур уңышларга иреште.

Төньяк Кавказда Кызыл Армия немецларны 300 километрдан артыграк ераклыкка алып ташлады һәм аларны тагын да куууны дәвам иттерә, ә мактанчык немец гаскәрләре, совет гаскәрләренең ударлары астында, коралларын һәм яралыларны ташлап калдырып, чигенүләрендә дәвам итәләр.

Үзәк фронтта Кызыл Армия немецларны җитди җиңелүләргә дучар итте һәм стратегик әһәмияткә булган мөһим пунктны—Великие Луки шәһәрен һәм тимер юл узелын алды.

Воронеждан көньяктарак Кызыл Армия немец-фашист басып алучыларга куәтле удар ясады. Биредә дә совет гаскәрләре немец оккупантларны меңәрләп-меңәрләп кыралар, уннарча мең кешеләрне плән алалар, дошманның коралларын кулга төшерәләр һәм халык яши торган меңнәрчә пунктларны гитлерчы пычраклардан азат итәләр.

Маныч районында, Донның түбәнге агымы һәм Төньяк Донец районнарында безнең гаскәрләр дошманны куып баруларында дәвам итәләр.

Моннан өч кенә көн элек әле бөтен совет халкы, Ленинград һәм Волхов фронтлары гаскәрләренең Ленинград блокадасын өзгәнлекләре турындагы хәбәрне ишетеп гаять зур шатлык кичерделәр.

Оборона Халык Комиссары иптәш Сталин үзенең 1942 нче ел 7 нче ноябрь приказында: «Кызыл Армиянең яңа ударлары көчен дошманның татыр көне ерак түгел» диде.

Бүгенге көнне безнең бөек юлбашчыбыз һәм полководецыбыз иптәш Сталинның сүзләре ничек тормышка ашырылуны, йөгәннәреннән ычкынган немец-фашист басып алучыларга Кызыл Армиянең ничек итеп удар артыннан удар ясавын бөтен дөнья күрә. (**Көчле кул чабулар**).

1942 нче елның 19 нчы ноябреннан 1943 нче елның 19 нчы январена кадәр безнең гаскәрләр һөҗүменең ике ае эчендә совет-немец фронтында немец фашистлары армиясе түбәндәге югалтуларга дучар булды: безнең гаскәрләр 200.000 нән артык кешене плен алдылар. Шул вакыт эчендә немец фашистлары армиясе, үтерелгән килеш кенә дә, 500.000 нән артык солдат һәм офицерларын югалтты. Шул ук вакыт эчендә немецлар 6.000 нән артык танк, төрле калибрларда 12.000 чамасы орудие, 3.500 гә якын самолет, шулай ук бик күп сугыш припаслары, пулеметлар, винтовкалар, автомашиналар һәм башка төрле сугыш милекләре югалттылар.

Совет гаскәрләренең ике ай эчендәге һөҗүмендә немец армияләренең кешеләрен һәм коралларын гаять зур югалтулары немец-фашист гаскәрләрнең авыр җиңелүләрен күрсәтәләр. Бу югалтулар немецларның көчләрен какшаттылар, дошман гаскәрләренең чыдамлылыгын җитди рәвештә йомшарттылар һәм киресенчә, Кызыл Армиянең җиңүләре совет гаскәрләренең, совет тылының сугышчан рухын һәм оешканлыгын ныгыттылар һәм Кызыл Армиянең немецлар армиясен кыйный ала һәм уңышлы рәвештә кыйный икәнлеген исбат иттеләр.

Дошман гаскәрләре тылында киң күләмдә җәелеп киткән партизаннар хәрәкәте совет халкының Ленин—Сталин эшенә чын күңелдән бирелгәнлегенең ачык дәлиле булып тора. Дошман тылында совет патриотлары үз ватаннарының турылыклы уллары булып калдылар һәм безнең җирләребезне коллыкка төшерүче фашистлардан азат итү өчен үз-үзләрен аямыйча көрәшәләр. Партизаннар көрәшен буып бетерү өчен гитлерчы җәза отрядларының барлык көчәнүләренә дә карамастан, совет партизаннары Кызыл Армиягә үзләренең ярдәмнәрен арттыралар, дошман тылларын кыю рәвештә тар-мар итәләр, кабахәт оккупантларны кыралар, тимер юл составларын юлдан чыгарып аударалар, күперләрне шартлаталар, дошманның элемтәсен һәм аның коммуникацияләрен җимерәләр. Партизаннар хәрәкәте көннән-көн киңәя һәм үсә бара.

Немец гаскәрләренә Кызыл Армия тарафыннан ясалган ударлар хәрби яктан гына түгел, бәлки халыкара политик яктан да зур әһәмиятле урын тоталар.

Кызыл Армиянең уңышлары аңа азатлык сөюче барлык халыкларның тирән симпатиясен яулап алды. Хәзерге көндә ул гаять тирән ихтирам белән чолганып алынды, чөнки нәкъ менә ул,—Кызыл Армия,—Гитлер Германиясенә каршы һәм аның ярдәмчеләренә каршы сугышның бөтен авырлыгын үз өстендә күтәреп алып бара.

Шулай ук түбәндәге хәлләрне игътибарга алмыйча китәргә мөмкин түгел: сугышның барышында Германия империализмының идеологиясе тамырыннан җимерелде, ахыргача фаш ителде. Европа халыклары оккупацияләнгән илләрдә гитлерчылар тарафыннан урнаштырыла торган «яңа тәртип» дип атала торган нәрсәнең ничек икәнлеген эштә күреп белделәр. Гитлерчыларның башка халыкларны кырып бетерүдән башка яки аларны колларга әверелдерүдән башка төрле бернинди дә максатлары юк икәнлеген Европа халыклары ачы тәҗрибәдә күреп ышандылар.

Кызыл Армиянең уңышлары Гитлерның Европадагы булышчыларының—итальяннарның, румыннарның, венгерларның, финнарның—немецлар армиясе көченә ышанычын как-

(Дәвамы 2 нче биттә).

Соңгы сәгатьтә

Безнең гаскәрләр көньякта Ставрополь шәһәрен алдылар

21 нче январьда Закавказье фронты гаскәрләре каты сугыш нәтиҗәсендә Ставрополь шәһәрен алдылар. Пленныйлар алынды һәм трофейлар кулга төшерелде.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

Иптәш А. С. Щербаков докладының дәвамы

шатты, хәзер үк инде фашистлар шайкасында катнашучылар арасында таркалыш тудырды, ә киләчәктә тагын да зуррак таркалыш китерәчәк. Кызыл Армиянең ударлары, ниһаять, Гитлерның баш-баштаклыгына кол булырга теләмәгән, буйсынырга теләмәгән халыкларны талау һәм бетерү максаты белән берләшкән бу юлбасарлар өерен тагын да таркалуга һәм җимерелүгә китерәчәк.

Кызыл Армиянең һөҗүме башлануның беренче атналарында гитлерчы идарәчеләр Совет-Германия фронтында немец гаскәрләренең бик зур җиңелүен Германия халкыннан һәм бөтен дөньядагы җәмәгатьчелек фикереннән яшерергә маташып бик нык көчәнделәр. Ләкин без капчыкта ятмый, һәм шул чакта Гитлер командованиесе сугыш вакыйгаларына үзенчә аңлатма бирергә, әлбәттә, ялган аңлатма бирергә маташты. Уйлап карагыз,—Гитлер һәм аның иярченнәре нинди көлке һәм ахмак хәлгә килеп төштеләр.

1942 нче елның 30 нчы сентябрендә Гитлер немец рейхстагында мактанчыклык белән түбәндәгеләрне белдерде: «Без Сталинградка штурм ясыйбыз һәм аны алырбыз—сез моңа ышана аласыз..: Без нәрсәне булса да алсак, безне аннан кире кузгатырга мөмкин түгел». Гитлерның һәрбер сүзе бушка мактану икәнлеге хәзер һәркемгә ачык. Гитлерчылар Сталинградны алмадылар. Ул гына да түгел, немец гаскәрләре Сталинградтан 300 километрдан артык ераклыкка алып ташландылар, ә Сталинград янында чолганып алынган немецларның 22 дивизиясен бетерү тәмам булып килә. Гитлер үзенең бу дивизияләрен кая булса да «кузгатырга» бик шатланып теләр иде, ләкин ошбу нәрсә аның кулыннан килми инде. **(Залда җанлылык).**

Гитлерның иярчене Геббельсның да алдан әйтеп куюлары барып чыкмады. 1942 нче елның көзендә, нейтраль илнең җәмәгатьчелек фикеренә басым ясау теләге белән, Геббельс Төркия журналистлары белән беседасы вакытында, кышка кадәр Кызыл Армия тар-мар ителәчәк, дип ышандырган иде. Ул болай дигән: «Мин үземнең сүзләремне һәрвакыт үлчәп сөйлим, мин ышаныч белән әйтә алам: кышка кадәр рус армиясе Германия өчен куркынычлы булмаячак инде. Мин бу сүзләрне әйткәндә һәрвакыттагы кебек ышанам ки, вакыйгалар мине алдамаячаклар. Мин сездән бу турыда берничә айдан соң хәтерегезгә төшерүегезне үтенәм». Бу берничә ай үтте инде, Геббельсның бу тапкыр да ялганлатанлыгы һәркемгә ачык мәгълүм булды. Кыш керүгә Гитлер юк итәргә вәгъдә иткән Кызыл Армия хәзерге көндә немец гаскәрләренә көчле ударлар ясый һәм кайчан булганга караганда да хәзер немец оккупантлар өчен тагын да куркынычрак булып тора. **(Кул чабулар).**

Соңгы атналарда немец командованиесе «көнчыгыш фронттагы» хәл турында берничә тапкыр түбәндәге рәсми белдерүне игълан итте: «Алга чыгып торган терәк пунктларны кире алу юлы белән Германия гаскәрләренең фронт линиясен планлы рәвештә кыскартуны үткәргәнлекләре Берлинда мәгълүм булды. Донның урта агымы районында хәзерге вакытта бик каты сугышлар бара. Рус гаскәрләре кайбер уңышларга ирештеләр, шулай да әйтергә мөмкин, руслар үзләренең операцияләрен Германия командованиесе тарафыннан күздә тотылган планда алып баралар». **(Бөтен залда көлү).** Күрәсез—Гитлер командованиесе үзенең ялганында шул кадәр буталган ки, артык бер кая да барырга мөмкин түгел.

Чынлап та, гитлерчылар шушындый мәгънәсез сүзләрне игълан итүләре белән үзләренең хәрби сводкаларын укучыларны һәм тыңлаучыларны бөтенләй җүләрләр дип исәплиләр күрәсең, чөнки «фронт линиясен тигезләү» турында, оборонаның «уңайлырак чикләрен» алу турында, вакыйгаларның «Германия командованиесе тарафыннан күздә тотылган план буенча» һәм аның инициативасы буенча алга барулары турында һ. б. мондый мәгънәсез сүзләр нәрсәне күрсәтәләр соң? Әгәр дә Гитлер ставкасының бу хәбәрләренә җитди төс бирсәң, ул, Сталинградка килү юлларында немецларның, румыннарның һәм итальяннарның 36 дивизиясе Кызыл Армия тарафыннан юк ителүе, Сталинград янында немецларның 22 дивизиясенең чолганып алынуы һәм тар-мар ителүе немец командованиесенең планында күздә тотылган булып чыга;

200.000 нән артык немец, румын, итальян һәм венгер солдатларының һәм офицерларының совет гаскәрләре тарафыннан пленга алынулары Гитлер ставкасы инициативасы буенча эшләнгән булып чыга; **(көлү).**

1942 нче елның җәендә һәм көзендә Төньяк Кавказ районнары өчен немецлар үзләренең бик күп ун меңнәрчә башлары белән түләгәннәр иде. Хәзер инде ул районнар немецлар армиясе тарафыннан оборонаның уңайлырак чикләрен алу максаты белән калдырылган булып чыга;

Сталинград белән Дон арасында, Дон белән Төньяк Донец арасында элек немецлар тарафыннан оккупацияләнгән зур территориянең тазартылуы фронт линиясен тигезләүне теләгәнлектән үткәрелгән булып чыга!

Совет-немец фронтындагы эшләрнең хәлен ялганга тәмам чумган һәм буталып беткән гитлерчыларның болай аңлатуларыннан тавыклар да көләрлек түгелмени соң? Немецлар командованиесе надан һәм ахмак рәвештә ялганлый! Гитлерчы идарәчеләрнең Совет-Германия фронтындагы чын хәлне яшерүләре тормышлары яхшы булганлыктан түгел ул!

Ватан сугышының барышыннан килеп чыга торган нәтиҗәләр һәм сабаклар нинди? Алар турында кыскача әйтергә мөмкин.

Үзенең азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен үз-үзен аямыйча көрәшүче халыкны җиңәргә мөмкин булмавы турындагы кагыйдә бу сугышта элекке сугышларга караганда да зуррак көч белән яңадан расланды. Монда, барлык мәсьәләләрдәге кебек үк, бөек Ленин хаклы булды, азатлык җимешләрен татыган, үзенең властен төзегән, үзенең бөек, яхшы идеяләре өчен көрәшергә теләгән һәм көрәшә белә торган халык теләсә нинди көрәштән, бу көрәш ничек кенә авыр һәм кыен булмасын, дошман нинди генә каты һәм явыз булып чыкмасын, барыбер халык җиңеп чыгачак дип партиябезне өйрәткән бөек Ленин хаклы булып чыкты.

Кызыл Армияне тар-мар итү турында һәм Советлар Союзын яулап алу турында немец империализмының планнары хәзер инде тәмам җимерелде. Сугышның агымы, барышы, тенденцияләре үзгәрде һәм ул Гитлер армиясе файдасына түгел, бәлки Кызыл Армия файдасына үзгәрде. Ераграк барган саен өстенлекләр безнең якта булачак. Кызыл Армиянең бу өстенлекләрдән ахырынача файдалана беләчәге һәм аларны тормышка ашыра алачагы турында шикләнмәскә мөмкин. Менә шуның өчен дә совет халкы киләчәккә шундый ышаныч белән карый.

Коллыкка төшерүче гитлерчыларга каршы һәм аларның кеше ашаучылык ниятләренә каршы сугышның барышында хәзерге заман халыкларының күпчелеге берләште. Шул уңай белән Гитлерга каршы булган дәүләтләрнең блогы торган саен тыгызлана бара һәм аларның Италия—Германия коалициясен җиңәргә тулы ышанычлары бар һәм алар җиңәчәкләр.

Безнең армиябез сугышның 19 ае эчендә чагыштырылмаслык дәрәҗәдә сугыш тәҗрибәсе белән баеды, тулысынча хәзерге заман армиясе булып, тагын да оешканрак булып әверелде, үз кулына иң яңа сугыш техникасын алды һәм хәзерге заман сугышының иптәш Сталин тарафыннан эшләнгән фәне буенча сугыша. Иптәш Сталин тарафыннан безнең бөек илебезгә лаеклы дәрәҗәгә күтәрелгән совет сугыш сәнгате Кызыл Армиянең җитди җиңүләре төсендә һәм дошман армияләренең авыр җиңелүләре төсендә үзенең җимешләрен бирде инде.

ВАТАН СУГЫШЫНДА СОВЕТ ТЫЛЫ

Владимир Ильич Ленин безне болай дип өйрәтте: «Сугышны **чынчынлап** алып бару өчен нык, оешкан тыл кирәк. Иң яхшы армия, революция эшенә иң чын күңелдән бирелгән кешеләр, әгәр дә алар җитәрлек дәрәҗәдә коралланмаган, азык белән тәэмин ителмәгән, өйрәтелмәгән булсалар, дошман тарафыннан кичекмәстән кырылып бетәчәкләр» (XXII нче том, 304 бит).

Ленинның бу сүзләре хәзерге сугыш шартларында, гражданнар сугышы һәм чит ил интервенциясе елларындагыга караганда да зуррак әһәмияткә ия булып тора. Хәзер сугыш хәрәкәтләрендә сугыш техникасы узган сугышлардагыга караганда тагын да зуррак роль уйный. Моңа тагын шуны өстәргә кирәк: хыянәтчел рәвештә безгә һөҗүм иткән дошман бөтен Көнбатыш Европаның диярлек ресурсларына таяна.

СССР га каршы сугыш башлаганда немецлар беренче ударлардан соң ук безнең промышленностебыз һәм авыл хуҗалыгыбыз җимерелер дип һәм фронтны корал белән, сугыш припаслары, азык белән тоткарсыз тәэмин итә алмаслар дип, илдә хуҗалык ягыннан җимерелү башланыр дип исәп тотканнар иде. Немецлар үзләренең исәпләрендә бик нык ялгыштылар. Әлбәттә, немец басып алучыларга каршы сугышта безнең илебезгә килгән югалтулар берни дә тормый дип һәм безгә аларның бернинди дә әһәмияте юк дип ышандыру ахмаклык булыр иде. Без шактый территорияне югалттык, ә бу исә территория белән бергә кешеләрне дә, ашлыкны, металлны, ягулыкны, тимер юлларны, промышленность продукциясен дә югалттык дигән сүз. Кызыл Армиянең һәрбер командиры һәм һәрбер сугышчысы бу турыда үзенә тулы отчет бирергә тиешле. Безнең илебез җитди югалтуларга дучар булды. Шуның белән бергә, әһәмиятле промышленность һәм авыл хуҗалыгы районнарының немецлар тарафыннан басып алынуы белән бәйләнгән гаять зур кыенлыкларга да карамастан Кызыл Армиянең тылы үз бурычларын үтәргә һәм фронтны барлык кирәк әйберләр белән тәэмин итүне җайга салырга булдыра алды. Совет промышленностен җимерүләре турында бик күп кычкырган немецлар хәзер инде, руслар бу кадәр күп коралны кайдан алалар икән? дип үз-үзләренә һаман да ешрак сорау бирә башлыйлар.

Безнең илебез Совет хөкүмәте һәм партия җитәкчелегендә үзенең хуҗалыгын сугыш шартларында шулай оештырырга булдыра алды ки, фронт барлык кирәк әйберләрне үз вакытында һәм кирәкле күләмнәрдә ала.

Монда безнең дәүләтебез безнең илебездәге халыклар алдында һәм үткән бөтен тарихтагы бөтен дөнья халыклары алдында кайчанда булса торганга караганда да кыенрак бурычларны хәл итте. Мондый бурычларның берсе промышленностьны куркыныч астындагы районнардан илебезнең көнчыгыш районнарындагы яңа базаларга күчерүдән гыйбарәт булды. Беренчедән, безнең промышленностебызны дошман кулына бирмәскә, мөмкин булганнарның бөтенесен алып китәргә, алып китәргә мөмкин булмаганнарын юк итәргә кирәк булды. Бу бурыч үтәлде. Гитлерчыларга безнең промышленность байлыкларыбыз хисабыннан баерга туры килмәде.

Ләкин бурыч куркыныч астындагы районнардагы предприятиеләрнең җиһазларын чыгаруда гына түгел иде. Хәер анысы да җитәрлек дәрәҗәдә катлаулы эш иде. Шуның өстенә тагын ул предприятиеләрне яңа урыннарда тизрәк аякка бастырырга, аларны эшләтә башларга кирәк иде. Димәк, сүз җиһазларны гади күчерү турында гына бармады, бәлки промышленностьның тоташ тармакларын икенче базаларга күчерү турында, күп йөзләрчә фабрикаларны һәм заводларны көнчыгышка күчерү турында һәм шуның өстенә тиңдәше булмаган кыска срокларда күчерү турында барды. Предприятиеләр яңа урыннарда тиз аякка бастырылдылар һәм эшли башладылар. Аларның күбесе хәзер продукцияне сугышка кадәргедән дә күбрәк бирә.

Предприятиеләрне икенче базага күчерү белән бер рәттән шуның шикелле үк катлаулы булган икенче бер бурычны ашыгыч рәвештә хәл итәргә—көнчыгышта ягулык, электр энергиясе, кара һәм төсле металлар җитештерүне киңәйтергә, тимер һәм марганец рудасы чыгаруны, кокс җитештерүне арттырырга һ. б. эшләргә кирәк иде. Моның өчен, эшләп килә торган предприятиеләрдән, шахталардан һәм рудниклардан файдалануны яхшырту белән бер рәттән, яңа предприятиеләр салырга һәм булганнарын киңәйтә барырга кирәк булды. Бу кыен бурычны да без уңышлы үтәп киләбез. Көнчыгышта промышленность буенча капиталь төзелеш киң күләмдә җәелеп китте. Яңа домналар, мартеннар, электр станцияләре, шахталар, рудниклар салына. Төзелешнең күп кенә бик әһәмиятле объектлары инде эшли дә башладылар. Бу яңа төзелеш хәтта безнең илебездә дә әлегәчә булмаган темплар белән алып барыла.

Сугыш заманының иң кыен бурычы—промышленность һәм транспорт өчен яңа эшчеләр сайлап алу һәм әзерләү бурычы хәл ителде. Сугыш алдыннан иптәш Сталин инициативасы белән оештырылган һөнәр һәм тимер юл училищелары һәм ФЗӨ мәктәпләре бу эштә гаять зур роль уйнадылар һәм уйныйлар. Сугыш башланганнан бирле алар

(Дәвамы 3 нче биттә).

Иптәш А. С. Щербаков докладының дәвамы

промышленностька һәм транспортка бер миллион чамасы өйрәтелгән эшче бирделәр. Шуның белән бергә, промышленностька, хезмәт резервлары системасыннан тыш, күп йөз меңнәрчә яңа эшчеләр һәм бигрәк тә хатын-кызлар килде. Алар кыска гына вакыт эчендә үз эшләренең техникасын үзләштерделәр һәм хәзер фронт өчен уңышлы рәвештә эшлиләр.

Ватан каршындагы бурычны аңлау безнең халкыбызда гомуми хезмәт күтәрелеше тудырды. Бу күтәрелеш Бөтенсоюз социалистик ярышының әлегәчә күрелмәгән колачында чагылды. Безнең предприятиеләрдә совет патриотлары дошманны тар-мар итүгә үзләренең барлык көчләрен бирәләр. Совет кешеләренең үз-үзләрен аямыйча геройларча эшләүләре—бу, аларның үзләренең совет ватаннарына карата иң тирән мәхәббәтләренең, нинди генә корбаннарга һәм авырлыкларга да барырга әзер торуларының, нинди генә кыенлыкларны да җиңәргә әзер торуларының чагылышы. Бары тик дошманны җиңәргә генә булсын.

Билгеле, безнең промышленность алдында зур кыенлыклар торды һәм тора. Бу кыенлыклар, аерым алганда, кара металлургияне һәм ягулык-энергетика базасын үстерүнең промышленность һәм бөтен халык хуҗалыгының үсеп бара торган ихтыяҗларыннан билгеле дәрәҗәдә артта калуыннан гыйбарәт. Ләкин болар җиңелә торган кыенлыклар.

Безнең промышленностьның сугышчан бурычы—кара металлургия буенча яңа агрегатларны, электр станцияләрен, яңа шахталарны һәм рудникларны төзүне һәм эксплоатациягә бирүне тизләтүдән, шулай ук бер кадәр куәтләрдән файдалануны яхшыртудан гыйбарәт.

Хәзер чималга, ягулыкка, электр энергиясенә, металлга экономия ясау һәм һәртөрле җирле байлыкларны туплау гаять зур әһәмият ала. Тәҗрибә шуны күрсәтә: җирле инициативаның фронтны тәэмин итүне арттыру һәм киң куллану товарлары эшләп чыгаруны арттыру өчен зур өстәмә чыганак булуы мөмкин.

Сугыш авыл хуҗалыгының эшендә шактый кыенлыклар тудырды. Колхозлар һәм совхозлар авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерүне арттырырга, алар өчен күп кенә яңа культуралар җитештерүне үзләштерергә һәм үстерергә, әһәмиятле авыл хуҗалыгы районнарын дошманның басып алуы нәтиҗәсендә безнең илебезгә килгән зыянның мәгълүм өлешен капларга тиеш булдылар.

Безнең авыл хуҗалыгы бу бурычларны башкарып чыкты. 1942 нче елны чәчү мәйданы 1941 нче елга чагыштырганда 2 миллион гектарга артты. Сугыш башланганннан бирле көнчыгышта бөртекле орлыкчылык базасы киңәйтелде, бәрәңге, яшелчә, шикәр чөгендере һәм башка төрле азык һәм техника культуралары чәчүлекләре арттырылды.

Авыл хуҗалыгы эшләрендә хезмәткә яраклы барлык олы кешеләр генә түгел, бәлки картлар да, яшь үсмерләр дә катнашты. Колхозчыларга ярдәмгә эшчеләр, хезмәткәрләр һәм шәһәр укучылары килде. Шушыларның бөтенесе нәтиҗәсендә күп колхозларда авыл хуҗалыгы эшләрендә катнашучыларның гомуми саны кимемәде генә түгел, хәтта сугышка кадәргегә чагыштырганда артты да.

1942 нче елны язгы чәчү, игеннәрне урып-җыю, шулай ук көзге чәчү өлкәләрнең күпчелегендә 1941 нче елга караганда яхшырак, тизрәк һәм оешканрак төстә үткәрелде.

Безнең колхозлар һәм совхозлар «халыкны һәм Кызыл Армияне азык белән, ә промышленностебызны чимал белән намуслы рәвештә һәм төгәл тәэмин итәләр» (Сталин).

Авыл хуҗалыгындагы бу уңышларның нигезе бездә Ленин васыятьләре буенча төзелгән колхоз строе булудан гыйбарәт. Билгеле, вак индивидуаль крестьян хуҗалыгы сугыш авырлыкларына түзә алмаган булыр иде, армияне һәм илне кирәкле азык һәм чимал белән тәэмин итә алмаган булыр иде. Сугыш аркасында килеп чыккан кыенлыкларны Совет дәүләте бары тик колхоз строе аркасында гына җиңә.

Явыз фашист басып алучыларны тар-мар итүдә Кызыл Армиягә булышлык итү өчен колхозчы крестьяннар барлык көчләрен бирәләр. 1942 нче елның язында күп колхозларда оборона фондына планнан тыш чәчүлекләр оештырылды. Алар Кызыл Армиягә өстәмә рәвештә шактый күп ашлык һәм яшелчә бирделәр. 1942 нче елның ахырында, Тамбов һәм Саратов колхозчылары башлап җибәрүе буенча, танклар колонналары һәм сугыш самолетлары эскадрильяләре төзелешенә акча җыю башланды. Колхозчылар, акча белән бергә, Кызыл Армия фондына җәмәгать фондларыннан һәм үзләренең запасларыннан ашлык, яшелчә, ит һәм башка продуктлар бирәләр.

Алдынгы кешеләрнең инициативасы илебездәге барлык колхозчылар, эшчеләр һәм хезмәткәрләр массасын кузгатты һәм илебез оборонасы кирәкләренә индивидуаль взносларның гаять дәрәҗәдә күп булып агылуын китереп чыгарды. Кызыл Армия өчен танклар, самолетлар һәм башка кораллар төзелешенә акча җыю буенча халыкның патриотлык хәрәкәте колхозчы крестьяннар интереслары белән совет ватанының язмышы аерылгысыз төстә бәйләнгәнлекне ачык күрсәтә. Тарихта беренче тапкыр буларак крестьяннар сугышта үз дәүләтләрен, аларга ирекле, культуралы, таза тормыш тәэмин иткән дәүләтне саклыйлар. Тарихта беренче тапкыр буларак крестьяннар сугышны үз эшләре дип, үзләренең алдагы язмышлары бу сугышның нәрсә белән бетәчәгенә бәйләнгән эш дип карыйлар.

Хәзер колхозлар алдында гаять әһәмиятле ике бурыч тора: беренчесе—дәүләткә ашлык тапшыруны төгәлләү. Күп кенә өлкәләрдә инде ашлык тапшыруны тәмам иттеләр. Шулар белән беррәттән әле артта калучы өлкәләр һәм районнар да бар. Аларның бурычы—үзләренең дәүләт һәм Кызыл Армия каршындагы йөкләмәләрен иң кыска срокта тулысынча үтәүдән гыйбарәт.

Хәзерге вакытта колхозлар алдында тора торган гаять әһәмиятле икенче бурыч—1943 нче елгы чәчүгә әзерлек. 1943 нче елны без үткән елга караганда авыл хуҗалыгы продуктларын күбрәк алырга тиешбез. Бу нәрсә безне 1943 нче елгы язгы чәчүгә җентекләп әзерләнү өчен кышкы чордан үрнәк булырлык төстә файдаланырга мәҗбүр итә.

Бөек ватан сугышы көннәрендә, эшчеләр һәм колхозчылар белән берлектә, совет интеллигенциясе дә үзенең барлык көчен һәм белемен немец-фашист басып алучыларга каршы көрәш эшенә бирә. Безнең интеллигенциябез, бигрәк тә сугыш башланганнан бирле, яңа төр кораллар иҗат итүче һәм аларны җитештерүне оештыручы совет конструкторларының, инженерларының, техникларының нәрсәгә сәләтле икәнлекләрен күрсәтте. Илебезнең көнчыгыш районнарында яңа чимал һәм энергетика байлыклары эзләп табу буенча һәм алардан файдалануда яңа методлар уйлап табу буенча совет галимнәренең эше илебезнең хәрби куәте өчен гаять дәрәҗәдә әһәмиятле. Промышленностьны хәрби ладка үзгәртеп кору эшендә, предприятиеләребезне көнчыгышка күчерү эшендә, яңа заводлар төзелешендә безнең инженер-техник работникларыбыз гаять зур эш эшләделәр. Совет врачлары һәм барлык медицина работниклары ватан каршында үзләренең бурычларын үз-үзләрен аямыйча үтиләр. Алар безнең күп һәм күп меңнәрчә сугышчыларыбызның тормышларын саклап калдылар. Сугыш башланганнан бирле совет агрономия фәне работниклары, совет укытучылары, сәнгать һәм әдәбият работниклары зур эш үткәрделәр. Совет интеллигенциясе, патриотизм күтәрелеше белән чолганып алынган хәлдә, фронтта һәм тылда эшчеләр һәм крестьяннар белән кулга-кул тотышып эшләгән хәлдә, явыз фашист басып алучыларны тар-мар итүдә Кызыл Армиягә булышлык күрсәтә.

Узган ел эчендә партиябез үткәргән бештыру эше бөтен илебезне үзгәртте, ул безнең совет тылындагы кешеләрне дә үзгәртте. «Кешеләр җыйнакландылар, җебегәнлекләре кимеде, дисциплиналары артты, сугыш заманындагыча эшләргә өйрәнделәр, үзләренең ватан каршындагы һәм аны фронтта саклаучылар каршындагы—Кызыл Армия каршындагы бурычларын аңлый башладылар...

Безнең илебезнең әле беркайчан да мондый нык оешкан тылы булганы юк иде» (Сталин). **(Кул чабулар).**

СОВЕТЛАР СОЮЗЫНЫҢ КӨЧЛЕ ҺӘМ ҖИМЕРЕЛМӘСЛЕК БУЛУЫНЫҢ ЧЫГАНАКЛАРЫ

Бөтен дөнья, безнең дусларыбыз һәм дошманнарыбыз, үзләренә бер үк төрле сорауны бирәләр: Кызыл Армиянең тиңдәшсез нык торучанлыгының һәм геройлыгының сәбәбе нәрсәдә, Советлар Союзының көчле, куәтле һәм җимерелмәслек булуының чыганагы нәрсәдә?

Бу сорауга җавапны безнең ватаныбызның соңгы чирек гасыр эчендәге тарихы бирә. Бөек Октябрь Социалистик революциясе нәтиҗәсендә, большевиклар партиясе җитәкчелегендә, Ленин һәм Сталин җитәкчелегендә, Советлар Союзы халыклары һәртөрле изелүдән азат булдылар, яңа иҗтимагый строй төзеделәр, чын халык власте, Совет власте урнаштырдылар. Тарихта беренче тапкыр буларак халыкның язмышы аның үз кулында, безнең илебездәге һәрбер хезмәт иясенең язмышы һәм интереслары гомумән ватан һәм дәүләт язмышына һәм интересларына кушыла. Совет власте—хезмәт ияләренең үз власте; аның көчләренең, ныклыгының, җиңелмәслегенең чыганагы шунда. Безнең илебездә һәрбер хезмәт иясе, немец-фашист басып алучыларга каршы бөек ватан сугышында үз властен—халык властен, үз азатлыгын һәм үз бәйсезлеген саклавын әйтә ала. Совет дәүләтенең көче аның эшчеләрнең, крестьяннарның һәм интеллигенциянең какшамаслык союзына таянуы белән аңлатыла. Совет строеның бөек көче нәкъ әнә шул союзда. Ватан сугышы барышында бу союз тагын да ныгыды һәм чынықты. Ә бу инде совет строеның ныклыгы тагын да артты дигән сүз. Совет дәүләте барлык расаларның һәм милләтләрнең тулы тигез хокуклылыгы нигезендә илебездәге барлык халыкларны нык берләшкән бердәм семья итеп туплады һәм шуның белән илебезнең көчен гаять дәрәҗәдә арттырды. Хәзер инде Совет Социалистик Республикалар Союзындагы һәрбер халык немец фашист басып алучыларга каршы изге сугышта азатлыкны, бәйсезлекне, үзе өчен һәм илебездәге халыкларның бөтен семьясы өчен бәхетле булу хокукын нык торып саклавын әйтә ала.

Тыныч төзелеш белән үткән 20 ел эчендә Советлар Союзының хезмәт ияләре Россиянең гасырлар буена килгән арталыгын бетерделәр һәм илебезне алдынгы дәүләткә әйләндерделәр. Илне индустрияләштерү һәм авыл хуҗалыгын коллективлаштыру буенча Ленин—Сталин планнары иң кыска тарихи срокларда тормышка ашырылды. Яңа, социалистик экономика төзелешенә һәртөрле изелүдән азат булган халыкның бөек иҗат көчләре һәм сәләте салынды. Массаның хезмәт геройлыгы аркасында безнең илебез индустриаль ил булып, колхоз иле булып, димәк көчле һәм куәтле ил булып әверелде. Безнең армиябезнең һәрбер сугышчысы, үткән бөтен дөнья сугышы вакытында патша армиясе солдатлары калган кебек коралсыз, сугыш припассыз һәм азыксыз калмаячагын белә. Бөтен совет халкының үз-үзен аямыйча безнең армиябезгә булышлык итүе—аның көч чыганагы, нык торучанлык һәм рухлану чыганагы булып тора, чөнки Кызыл Армиянең һәрбер сугышчысы үзенең артында бөтен совет халкы торганлыкны аңлый.

Совет халкының көче—аның җимерелмәслек мораль-политик бердәмлегендә. Хәзер безнең бөтен халкыбыз большевиклар партиясе тирәсенә, үзенең юлбашчысы иптәш Сталин тирәсенә беркайчан да булмаганча тупланган. **(Көчле кул чабулар).**

Ленин—Сталин партиясенең халык алдында гаять зур ышаныч казанганлыгын бөек ватан сугышы аеруча ачык итеп күрсәтте. Сугышның дәһшәтле һәм куркынычларга бәйле булган көннәрендә большевиклар партиясе сафларына үз-үзләрен аямаучы меңнәрчә яңа көрәшчеләр керәләр. Хәзер партиягә иң алдынгы кешеләр,—корбаннар бирергә генә түгел, бәлки дошманга каршы көрәшер өчен үзләренең тормышларын да бирергә әзер торучы кешеләр киләләр. 1942 нче елны большевиклар партиясе сафларына 1 миллион 340 мең хезмәт иясе кергәнлекне әйтү генә дә җитә. Бу факт үзе генә дә халыкның партиягә ышанычы нинди зур икәнлекне, Ленин—Сталин партиясенең халык белән нинди өзелмәс җепләр аша бәйләнгәнлеген күрсәтә.

Советлар Союзы халыклары ватаныбыз өстенә килгән куркынычның тирәнлеген аңладылар һәм үзләренең барлык материаль һәм рухани көчләрен дошманга каршы көрәш өчен туплыйлар. Россия тарихында патриотлык үрнәкләре аз булмады. Халыкның алдынгы вәкилләре ватан хакына үзләренең бөтен нәрсәләрен корбан иттеләр. Ләкин, хәзерге вакытта, немец империалистларына каршы азатлык сугышы көннәрендә без күрә торган шундый массовый геройлык, СССР дагы барлык халыкларның шундый бердәмлеге тарихта булганы юк иде әле. Безнең

(Ахыры 4 нче биттә).

Иптәш А. С. Щербаков докладының ахыры

халкыбыз беркайчан да әле хәзерге шикелле оешкан булганы юк иде. Бу хәл халыкка Ленин—Сталин партиясе кебек юлбашчының һәм оештыручының җитәкчелек итүе белән аңлатыла. Халык белән булган ныклы элемтәләр партиянең көчен арттыралар һәм партия тирәсенә тупланган халык—җиңелмәслек көч булып тора.

Үзенең хак эш өчен, изге һәм югары максат өчен, ватаныбызның намусы, азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен көрәшүен аңлау Кызыл Армиягә җиңелмәслек көч бирә. Безнең армиябезнең һәрбер сугышчысы үз тормышын һәм үз азатлыгын, үз семьясының, үз халкының тормышын һәм азатлыгын дошманны юк итми торып коткара алмаячагын аңлый. Я актык тамчы канга кадәр сугышырга һәм үз ватаныңны саклап калырга, яки үзеңне, үзеңнең семьяңны, үзеңнең халкыңны кеше ашаучы немецларга коллыкка бирергәме,—һәрбер совет сугышчысы алдында мәсьәлә әнә шулай тора. Шуңа күрә дә совет сугышчыларының массовый геройлыгы, аларның ныклык торучанлыгы һәм тырышлыгы, аларның дошманны җиңү осталыгын үзләштерүгә булган омтылышлы теләге бик аңлаешлы.

Кызыл Армия көчләренең, ватаныбыз көчләренең чыганаклары әнә шундыйлар. Шулар ярдәме белән совет халкы һәм Кызыл Армия немец басып алучыларны тар-мар итәр һәм безнең җиребезне фашист пычраклардан чистартыр.

ЛЕНИН БАЙРАГЫ АСТЫНДА, СТАЛИН ҖИТӘКЧЕЛЕГЕНДӘ БЕЗ ҖИҢӘРБЕЗ!

Безнең илебез өстенә килгән зур югалтуларга һәм корбаннарга да карамастан, ватан сугышы фронтларында хәл хәзер безнең өчен үткән елга караганда күп дәрәҗәдә яхшырак булып бара. Хәер, ул чагында да безнең армиябез дошманга куәтле ударлар ясаган иде. Моның шулай икәнлеген Верховный Баш Командованиесенең стратегия планнарын тайпылышсыз тормышка ашыручы совет гаскәрләренең уңышлы һөҗүме күрсәтә.

Сугышның үткән чорында Кызыл Армиянең оборона һәм һөҗүм операцияләрендә, немец-фашист басып алучыларга каршы каты көрәштә дошманны җиңү өчен шартлар яулап алынды һәм таза фундамент салынды.

Кызыл Армия сугышларда чыныкты һәм ныгыды, тагын да көчлерәк һәм оешканрак булып әверелде. Ул хәзерге заман сугышы тәҗрибәсе белән баеды, аның сугышчылары һәм командирлары бәрелешләр утында сугыш осталыгы нигезләрен уңышлы рәвештә үзләштерәләр. Совет гаскәрләре безнең чикләребезне саклап калырга гына түгел, бәлки дошманның оборонасын сындырырга, оста маневр ясап дошманны чолгап алырга һәм юк итәргә дә өйрәнделәр.

Сугыш барышында совет тылында оешканлык һәм дисциплина үсте, фронтка ярдәм итүнең куәтле яңа чыганаклары ачылды. Һич шик юк, җиребезне фашист басып алучылардан азат итү өчен көрәштә Кызыл Армия совет халкыннан һәрвакыт артканнан арта бара торган булышлык алыр.

Хәзер, дошманны җиңү өчен фундамент салынганнан соң, җирләребезне фашист басып алучылардан азат итү эше совет патриотларының барлык көчләрен җигүгә һәм илебезнең барлык мөмкинлекләрен туплауга бәйләнгән.

Кызыл Армия ирешкән уңышларга да карамастан, дошман инде җимерелде дип уйлау беркатлылык булыр иде. Дошманның көчләре какшатылган һәм соңгы чиккә китереп җиткерелгән, ләкин дошман әле көчле, немец басып алучылар әле яңа авантюраларга ташланырлар һәм аларның безгә күңелсезлекләр тудырулары мөмкин. Хәзер үз-үзеңне тынычландыру хәленә төшү—җиңү эше өчен куркынычлы һәм зарарлы булыр иде.

Эшләр начар барганда паникага һәм боеклыкка бирелү большевиклар өчен хас түгел. Большевиклар уңышлар белән исерә алмыйлар һәм аңа хаклы түгелләр. Уңышлардан баш әйләнү, уңышсызлыклардан паникага һәм боеклыкка бирелү шикелле үк, зарарлы. Хаклыкка ачык күз белән карарга кирәк. Безнең халкыбыз, Кызыл Армиябез, Хәрби Диңгез Флотыбыз алдында әле авыр сынаулар тора. Котырган немец-фашист юлбасарлар бандаларын һәм аларның союзникларын тәмам җиңү өчен вакыт кирәк, һәм ул сугышчылардан, эшчеләрдән, колхозчылардан, интеллигенциядән тагын да корбаннар таләп итә.

Җиңү өчен фронтта геройлык һәм ныклы дисциплина кирәк, тылда үз-үзеңне аямыйча эшләү, ныклы дисциплина һәм оешканлык кирәк. Һич шик булырга мөмкин түгел, гитлерчы басып алучыларның башка бернинди дә ил каршы тора алмаган басымына каршы торырга сәләтле булып чыккан безнең совет халкы немец фашистларын һәм аларның союзникларын тәмам бетерү өчен дә үзендә җитәрлек көч табар.

Барлык көчне фронтка булышлыкка! Барлык көч—җиңү өчен!

Яшәсен бөек совет халкы һәм аның героик Кызыл Армиясе һәм Хәрби Диңгез Флоты!

Яшәсен безне җиңүләргә чакыручы бөек һәм җиңелмәслек Ленин—Сталин Байрагы!

Яшәсен юлбашчыбыз һәм полководецыбыз иптәш Сталин! **(Бөтен зал көчле кул чаба. Барысы да урыннарыннан торалар).**

ТАНТАНАЛЫ-КАЙГЫЛЫ ҖЫЕЛЫШТА

Кичә, 21 нче январьда, Татар академия театры бинасында бөтен дөнья хезмәт ияләренең юлбашчысы Владимир Ильич Ленин үлүенә 19 ел тулуга багышланган тантаналы-кайгылы җыелыш булды. Бу көнне бирегә Казан шәһәренең партия, совет, профсоюз, комсомол оешмаларының һәм Казан гарнизонының вәкилләре, завод, фабрикаларның стахановчылары бөек Ленинны искә алу өчен җыелдылар.

Җыелыш нәкъ сәгать 7 дә башланды. Почетлы президиум сайлау тәкъдимен җыелышка катнашучылар зур хөрмәт белән каршы алдылар. Даһи Ленинның шәкерте бөек Сталин җитәкчелегендә илебезне җиңүләрдән җиңүләргә илтүче политбюро составыннан Сталин, Молотов, Калинин, Ворошилов, Каганович һәм башка иптәшләр көчле алкышлар астында сайландылар.

Җыелышта катнашучылар даһи Ленинны хөрмәтләү йөзеннән барысы да урыннарыннан торалар. Җыелыш ачыла. Бөек Ленин турында доклад өчен сүз ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Гафаровка бирелә.

Докладтан соң зур театр һәм татар дәүләт академия театры артистларының көче белән Ленинга багышланган зур концерт оештырылды. Концертның программасында Ленин тарафыннан яратылып тыңлана торган халык көйләре, ватан сугышы героизмына багышланып язылган шигырьләрне сөйләү һәм Ленин эшен дәвам итүче бөек Сталинга халкыбызның мәхәббәтен чагылдыра торган җырлар башкарылды.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

21 нче ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

21 нче январьга каршы төндә безнең гаскәрләр **Сталинград** районында, **Воронеждан** көньяктарак, **Төньяк Кавказда, Донның** түбәнге агымы, **Төньяк Донец** районында һәм **Ладога күленнән** көньяктарак элекке юнәлешләрдә сугышларны дәвам иттерделәр.

* * *

Сталинград районында шәһәрдән көнбатыштарак хәрәкәт итүче Н-че часть сугышчылары дошман оборонасының көчле рәвештә ныгытылган узелын алдылар. Сугыш кырында дошманның 300 гә якын үле гәүдәләре калды. 96 немец солдаты һәм офицеры плен алынды. Трофейлар кулга төшерелде. Шулар арасында 7 танк, 13 орудие, 39 пулемет һәм 2 радиостанция бар.

* * *

Көньяк фронтта безнең гаскәрләр дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, һөҗүмне дәвам иттерделәр Пролетарская тимер юл станциясен һәм шәһәрен немецлар аеруча нык торып саклап калырга тырыштылар. Анда «Германия» исемле СС полкы, туздырылган төрле частьларның калдыклары, күп артиллерия, танклар һәм ике батареяга якын алты көпшәле минометлар тупланган иде. Пролетарская өчен сугыш өч тәүлек буена диярлек көне-төне дәвам итте. Кичә безнең частьлар шәһәргә һәм станциягә бәреп кереп, урам сугышында дошманны тар-мар иттеләр һәм аның калдыкларын Манычның аръягына алып ташладылар. Икенче бер участокта Н-че гвардия часте, алга барып, халык яши торган ике пунктны алды. Бер артиллерия батареясы һәм 9 пулемет кулга төшерелде. Пленныйлар алынды.

* * *

Көньяк-көнбатыш фронт гаскәрләре сугыша-сугыша алга киттеләр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Бер участокта совет подразделениеләре 400 гитлерчыны юк иттеләр һәм 190 кешене плен алдылар. Н-че гвардия часте халык яши торган 3 пунктны алды, 3 орудие, 17 пулемет, 392 винтовка, 137.000 патрон, 4.000 снаряд һәм мина кулга төшерде. Каменск шәһәрен алган чакта дошманның автомашиналар төялгән 3 эшелоны, сугыш милекләре һәм азык тутырылган складлары, күп вагоннары, паровозлары һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Воронеж фронты гаскәрләре һөҗүм операцияләре алып баруны дәвам иттерделәр, ә көчләренең бер өлеше дошманның чолганып алынган дивизияләре әйләнәсендәге боҗраны кысты. Н-че часть, дошманны куып барып, 200 дән артык гитлерчыны юк итте һәм 360 дошман солдатын һәм офицерын плен алды. Бер танк, танкка каршы ата торган 4 орудие, сугыш йөкләре төялгән 60 олау һәм 10 мотоцикл кулга төшерелде. Икенче бер участокта венгерлар батальоны солдатлары һәм офицерлары аз гына сугышканнан соң коралларын ташладылар һәм пленга бирелделәр.

* * *

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр, дошманның каршылык күрсәтүен бастырып, халык яши торган берничә пунктны алдылар. Н-че гвардия часте сугышчылары, елга аша кичеп, немецларның тылына барып чыктылар һәм аларга кинәт атака ясадылар. Ике арада башланып киткән сугышта дошманның 300 дән артык солдат һәм офицерлары үтерелде. 100 немец плен алынды. 40 орудие, алты көпшәле 14 миномет, 180 пулемет һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Ставрополь партизаннарының өч отряды, һөҗүм итеп килүче Кызыл Армия частьлары белән бергә хәрәкәт итеп, Левокумский һәм Арзгир районнарында немец гарнизоннарын кырганнар. Партизаннар дошманның 117 солдат һәм офицерын юк иткәннәр һәм 87 кешене плен алганнар. 3 пулемет, 3 миномет, 214 винтовка һәм автомат, 74 мең патрон кулга төшерелгән. Шуның өстенә немецлардан 3.720 баш мөгезле терлек, 47 көтүдән торган сарык, 317 ат һәм 80 трактор сугышып алганнар. Немецлар боларны колхозлардан һәм халыктан талап алган булганнар.

* * *

Франция патриотлары дошманга каршылык күрсәтүне көннән-көн көчәйтәләр. Саннуа районында азат үкчылар немец солдатлары утырып бара торган поездга атканнар. Лорианда бер группа азат укчылар немецларның «Тодт» оешмасының әйбер складын яндырганнар. Бетюн-Лан тимер юлында сугыш йөкләре төяп бара торган бер эшелон юлдан чыгарылган. Һәлакәт нәтиҗәсендә 40 вагон җимерелгән.

БЕЗНЕҢ БҮЛӘКЛӘР

ШӨГЕР, 20 январь. **(Телефон буенча)** Кызыл Армиянең 25 еллыгы уңае белән фронтовикларга бүләкләр әзерләү киң җәелдерелде. «Беренче Май» колхозы члennары 50 пот бәрәңге, 5 сарык, 8 каз, 25 тавык, 20 килограмм бал һәм башка бик күп продуктлар җыйдылар. Иске Куак авылы колхозы членнары бу эштә аеруча яхшы катнашалар. Алар бер көн эчендә генә 93 сарык, 2 бозау, 8 пот ашлык, 60 пот бәрәңге, 75 каз һәм тавык, 80 килограмм ак май әзерләделәр. Куакбаш һәм Урдалы авылларында да сугышчыларга бүләкләр әзерләү уңышлы бара.

Ф. ГАЛИЕВА.
ВКП(б) райкомы инструкторы.

ЯРЫШКА КУШЫЛДЫЛАР

КАРГАЛЫ, 20 январь. **(Телефон буенча).** Кызыл Армия районының Киров исемендәге колхозы членнары Кызыл Армиянең 25 еллыгын яңа уңышлар белән каршылау өчен җиң сызганып эшкә керештеләр. Колхозда язгы чәчүгә әзерлек киң җәелдерелде. 33 сабанның 22 се, 93 тырманың 44 е ремонттан чыкты. Чәчү машиналарына һәм культиваторларга ремонт тәмам булды. 55 камытның да 20 се төзәтелде.

Ремонтта эшләүче тимерче Мостәкыймов, аның ярдәмчесе Лотфуллин иптәшләр, машинистлардан Садыйков һәм Абдуллин иптәшләр зур тырышлык күрсәтәләр. Сафин һәм Галимов иптәшләр камытларны төзәтүдә көнлек норманы арттырып үтиләр. Көл җыю, кар тоту эшләре дәвам итә. Орлык чистарту тиз көннән тәгәлләнә. Бу эштә эшләүче Хадимова һәм Сәлимова иптәшләр стахановча эшләп, башкаларга яхшы үрнәк күрсәтәләр.

Ш. ШАКИРОВ.

ГАЗЕТАБЫЗНЫҢ КИЛӘСЕ НОМЕРЫ 24 нче ЯНВАРЬДА ЧЫГАЧАК

Җаваплы редактор урынбасары ГАЛИМ РЯБКОВ.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—АТС 73—27, редактор урынбасары—АТС 76—29. секретарь—АТС 79—29. Партия тормышы бүлеге 14—75, промышленность-транспорт һәм хатлар бүлеге АТС 75—55, авыл хуҗалыгы бүлеге АТС 76—14, типография 36—60.

ЛФ 69 «Красная Татария» һәм «Кызыл Татарстан» издательствосының Александров исемендәге типографиясе № Заказ 129